ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05.07.2019 г. № 352

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында» 2017 елның 25 июлендә кабул ителгән 476 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын азык-төлек иминлеген тәэмин итү һәм туклануны оештыру максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларын 2017 елның 1 сентябреннән тукландыруны оештыру турында» 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 3 нче пунктындагы 9-12 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия бурычлы:

- җитешсезлекләр белән әзерләнгән ризыкларны кулланылыштан алырга;

- китерелә торган азык-төлек продуктларының медицина хезмәткәре белән берлектә тикшерергә, авырлыгын һ.б. тикшерергә;

- тикшерү нәтиҗәләре буенча, хокук бозуларны бетерүдә чаралар күрүне белем бирү оешмасыннан таләп итәргә».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф идарәсе башлыгы Фәретдиновка А.Р. йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов